**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.п. № 34 «20» сентябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 42 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (02.11.2015 №10, 04.05.2018 № 21, 13.11.2018 № 59, 13.12.2018 № 66, 21.06.2019 № 25, 25.11.2019 № 48, 19.03.2021 № 11 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 42 номерлы карарына (02.11.2015 № 10, 04.05.2018 № 21, 13.11.2018 № 59, 13.12.2018 № 66, 21.06.2019 № 25, 25.11.2019 № 48, 19.03.2021 № 11 карарлар редакциясендә) үзгәрешне кертергә:

- 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле алтынчы пунктчаны өстәргә:

«6) гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган сәүдә һәм административ-эшлекле үзәкләргә (комплексларга) һәм алардагы Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Министрлыгы күрсәтмәсе белән раслана торган исемлеккә кертелгән биналарга карата 1,2 процент.».

2. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aznakayevo.tatastan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм 2025-2027 еллар салым чорларына гамәлдә була.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советының бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис А.Л. Севостьянов